**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423190, с. Новошешминск, ул. Советская, 80
тел.: (84348) 2-31-00, факс: (8-4348) 2-20-22

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423190,Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80
тел.: (8-4348) 2-31-00, факс: (84348) 2-20-22

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2026 елның 24 апреленнән № 9-59

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 24 ноябрендәге 15-110 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 24 декабрендәге 15-110 номерлы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 20 апрелендәге 33-260 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 39-319 номерлы, 2024 елның 27 декабрендәге 51-398 номерлы, 2025 елның 18 июлендәге 58-446 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 24 декабрендәге 15-110 номерлы карары преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. «Нигезләмәнең 5 бүлегенең 5.4 пунктында «(икътисад буенча)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. Нигезләмәнең 8 бүлегенең 8.1 пунктындагы 4) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы белән килештереп, район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларын, Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары җитәкчеләрен вазыйфаларына билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар арасында вазыйфалар бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм Башкарма комитетның башка хезмәткәрләрен вазыйфаларына

билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;».

2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https:/novoseshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы Е.А.Тарнавский